БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«16» 05 2026 ел

**КАРАР**
№ 182

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче заты, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $281^1$ статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен расларга.

2. Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 6 июнендәге 264 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2015 елның 9 июнендәге 264 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач

район башкарма комитетының 2020 елның 15 маендагы 179 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «16» 05
182 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче заты, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затларның, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждение җитәкчеләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) бирү процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына (алга таба – эш бирүче) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырыла:

муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфаларына керүче затлар тарафыннан;

муниципаль учреждение җитәкчеләре тарафыннан - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасына тәгаенләнүче зат, вазифага керешкәндә, муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасына документлар тапшыру елыннан алдагы календарь елы өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны яки сайлау вазифасын башкару урыны буенча керемнәр, пенсия, пособие һәм башка түләүләр кертеп) алган керемнәре турында, аңа милек хокукында караган мөлкәт турында һәм үзенең милек хокукындагы йөкләмәләре турында (муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасына документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына булган хәл буенча), шулай ук затның муниципаль учреждение җитәкчесе вазифасына документлар тапшыру елыннан алдагы календарь елы өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (эш хакы, пенсия, пособие һәм башка түләүләрне кертеп) алган керемнәре, шулай ук аларга милек хокукында караган мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында (муниципаль учреждение

җитәкчесе вазифасына документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына кадәрге торыш буенча) мәгълүматлар тапшыра.

4. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң киләсе елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча:

чыгымнар (хисап чоры) турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чоры) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукында булган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

5. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган (аңа сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла) «БК белешмәләре» программа тәэминаты кулланылып тутырылган форма нигезендә әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында каралган белешмәләр Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарына тапшырыла.

6. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең күрсәтелмәвен яисә тулысынча күрсәтелмәвен йә хаталар булуын ачыклаган очракта, ул белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

7. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең күрсәтелмәвен яисә тулысынча күрсәтелмәвен йә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

8. Әлеге Тәртип нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, әгәр федераль

законнар тарафыннан дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләр булып саналмаса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

9. Әлеге Тәртип нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, күрсәтелгән белешмәләр аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаган очракта юкка чыгарылырга тиеш.

10. Аңа бәйле булмаган хәлләр аркасында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкин булмаган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе бу хакта «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган тәртиптә һәм срокларда эш бирүченең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә хәбәр итәргә тиеш.

11. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тапшыруы күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмау яки тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру эш бирүче тарафыннан аңа ышаныч югалтуга бәйле рәвештә аның белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең $7^1$ пункты).